**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**№ 16-РС** **2019 елның 3 апреленнән**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Орел авыл җирлеге генераль планына үзгәрешләр кертү проекты турында**

Территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктуралар үсешен, гражданнар ларның берләшмәләрен, юридик затларның һәм халык-хокукый оешмаларның мәнфәгатьләрен тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексының 23, 24, 25 маддәләренә, 2003 елның 6 октябреннән № 131-ФЗ “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законга, Татарстан Республикасының 2010 елның 25 декабреннән № 98-ЗРТ “Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында”гы Законына, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына нигезләнеп, Лаеш районы муниципаль район Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Орел авыл җирлеге генераль планына түбәндәге составта үзгәрешләр кертү проектын әзерләргә керешергә:

1) территориаль планлаштыру кагыйдәсе турында;

2) җирлекнең җирле әһәмияттәге объектларын урнаштыруның планлаштырылган картасы;

3) җирлек составына керүче торак пунктлар чикләре картасы;

4) җирлекнең функциональ зоналары картасы.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Орел авыл җирлеге генераль планына түбәндәге составта үзгәрешләр кертү проектын әзерләү 100 % күләмендә инвестор акчалары исәбенә башкарылачак, башкарылган эшләр өчен түләү килешү шартларына ярашлы төстә башкарылачак дип билгеләргә.

3. Генераль планга үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча эшләрнең түбәндәге этабын билгеләргә:

| № этапа | Эшләр этабы исеме |
|---|---|
| 1 | Генераль планга үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә контрактка кул кую,техник биремне әзерләү |
| 2 | Генераль планга үзгәрешләр кертү проектын әзерләү |
| 3 | Генераль планга үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык халык тыңлаулары (фикер алышу) үткәрү (шул исәптән ачык халык |

| | |
|---|---|
| | тыңлаулары беркетмәсен һәм аларның нәтиҗәләре турында бәяләмәне әзерләү) |
| 4 | Кирәк икән ачык халык тыңлаулары (фикер алышу) нәтиҗәләре буенча генераль планга үзгәрешләр кертү проектына корректировка ясау |
| 5 | Генераль планга үзгәрешләр кертү проектын Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнарында яраштыру |
| 6 | Генераль планга үзгәрешләр кертү проектын, ачык халык тыңлаулары (фикер алышу) нәтиҗәләре турында бәяләмәне, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының җыелма бәяләмәсен аларны раслау өчен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль район Советына җибәрү |

4. Генераль планны әзерләү буенча эшләр оештыруны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигы Д.Н.Хисмәтовка йөкләргә.

5. Бу карарны «Камская новь» («Кама ягы») район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы һәм Лаеш муниципаль районы рәсми сайтының Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).

6. Әлеге карар рәсми төстә басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан көченә керә.

7. Бу карар үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе М.В.Фадеевка йөкләргә.

**Башлык - муниципаль район**
**Советы рәисе вазифаларын башкаручы** **Т.П.Бурганова**